## О.Н. ГАЛИМОВАНЫҢ «ТАТАРЧА-РУСЧА-ЛАТИНЧА АҢЛАТМАЛЫ БАЛЫК АТАМАЛАРЫ СҮЗЛЕГЕ» (фәнни редактор: филология фәннәре докторы А.Ә. Тимерханов; бәяләүчеләр: филология фәннәре кандидаты И.И. Сабитова, филология фәннәре кандидаты М.К. Юматова. – Казан: ТӘһСИ, 2019. – 204 б.) ТУРЫНДА

Терминологик сүзлекләр татар лексикографиясе системасында аерым урын алып тора. Мәгълүм булганча, татар телендә терминологик сүзлекләр төзүнең күпьеллык тарихы һәм традицияләре бар. К. Насыйриның XIX гасыр ахырында дөнья күргән «Истиляхате җәгърәфия» сүзлеге (1890) – бу өлкәдә беренче тәҗрибә. Бүгенге көндә төрле фәннәргә караган күп кенә, шул исәптән биология терминнары сүзлекләре дә нәшер ителде. Бу хезмәтләрдә әлеге фәннең төп тармакларына – ботаника, зоология, анатомия, физиология, цитология, биотехнологиягә караган атамалар туплап бирелгән. Алар төрле принципларга нигезләнеп төзелгәннәр. Кайберләре русча терминга туры килерлек татарча сүз табу белән чикләнсә, икенчеләре русча терминнарга туры килгән татарча эквивалент бирү белән бергә, терминның мәгънәсен, эчтәлеген дә ачкан.

Биология терминнары бүгенге көндә, кайбер тармакларны исәпкә алмаганда, инде формалашкан төгәл системаны хасил итсә дә, аерым тематик төркемнәрдә төгәлсезлекләр әле дә очрый. Шуңа да тармак атамаларын камилләштерүдә, системага салуда терминологик сүзлекләрнең роле гаять зур.

Күптән түгел басылып чыккан «Татарча-русча аңлатмалы балык атамалары сүзлеге» – О. Галимованың күп еллар буе дәвам иткән фәнни тикшеренүләре нәтиҗәсе – балыкчылык лексикасындагы хата-җитешсезлекләрне мөмкин кадәр киметү, дөресләү максаты белән төзелгән сүзлек.

Автор тәкъдим ителгән кулланмада фәнгә билгеле ихтионимнардан Татарстан һәм Россия сулыкларында яшәүче балыкларның атамаларын гына биреп калмаган. Биредә аларның мәктәп дәреслекләрендә, фәнни-популяр әдәбиятта очраганнары да урын алган. Шулай ук ихтиологик, аквариумчылар әдәбиятларында, балыкчылар, балыкчы спортчылар форумнарында кулланылган океан, диңгез балыкларының атамалары да чагылыш тапкан.

О. Галимова балыкчылык атамаларын өйрәнүгә багышланган фәнни хезмәтендәге бай лексик материалга гына түгел, татар теленең аңлатмалы, диалекталь, телара, биология, авыл хуҗалыгы буенча атамалар сүзлекләренә дә таянган. Бер үк вакытта белешмәлекнең яңа ихтионимнар (экзотик балыкларның татарча атамалары) белән дә баетылуы аның кыйммәтен тагын да арттыра. Әлеге бай материал

җентекләп тикшерелеп теркәлгән, системага салынган. Сүзлек 168 ояга тупланган 1459 ихтионимны (шул исәптән 166 диалектализмны) һәм 485 классификация атамасын (ыруг, семьялык, отряд, классларны) үз эченә алган. Киң таралган күпкомпонентлы атамаларны җыеп, мәгълүматны бербөтен итеп бирү максатыннан, автор аларны алфавит тәртибендә оялап төзегән. Башта төп атама – балык (төр яки астөр) атамасы бирелгән. Беркомпонентлы төр атамасы булмаганда, берничә компонентлы терминнарга төп атама итеп ыруг яки семьялык атамасы алынган. Төп атамадан соң, алфавитка туры китереп, әлеге атама белән бәйле башка ихтионимнар, класс, отряд, семьялык, ыруг атамалары китерелгән. Мәсәлән:

**җилембалык** УКЛЕЙ, УКЛЕЙКА *Alburnus alburnus* Карп балыклар семьялыгыннан; Европа сулыкларында киң таралган, сырты соргылт күк, ян-яклары һәм корсагы көмешсу төстәге балык; балыкчылык хуҗалыгында әһәмияте зур түгел; *диал.* **йока сабак, йука чабак**
**җилембалыклар** УКЛЕЙКИ *Alburnus* Карп балыклар семьялыгыннан, төче су балыклары ыругы
… һ. б.

Биологик классификациядә төрле семьялыкка караган балыкларның атамалары сүзлектә, төп атамага карап, бер ояга урнаштырылган: *тәрәч* һәм *тешле тәрәч,* шулай ук *чуртан, Америка чуртаны, Амур чуртаны* һәм *диңгез чуртаны, макрель чуртаннар, скумбрия чуртаннар* атамалары бер ояда бирелгән.

Оядагы һәр термин яңа юлдан язылып, башта калын хәрефләр белән татарча ихтионим, аннан соң аның русча, латинча вариантлары китерелгән. Татар диалектларында да табылган очракта, балык атамалары *диал.* (диалектизм) тамгасы белән аерып күрсәтелгән:

**(гади) алабуга** ОКУНЬ (ОБЫКНОВЕННЫЙ) *Perca fluviatilis* Алабугалар ыругыннан; Европа, Төньяк Азия төче суларында иң киң таралган, койрыгының асты һәм корсак йөзгечләре кызыл төсле, киң яшькелт гәүдәсе биш-тугыз полосалы (шуңа ала булып күренә) ерткыч балык; *диал.* **әлүкін, алабога, алабыга, аламага**, **аламуга, бәймәт**
… һ. б.

Диалекталь атамаларны шул рәвешчә төп сүз вокабуласында бирү, беренчедән, сүзлек белән эшләүне җиңеләйтсә, икенчедән, тел байлыгын ачып бирүгә хезмәт итә.

Биологик систематикада гомумкабул ителгән латин атамаларын күрсәтү ихтионимнарны төгәлләштерү, системага салу максатына хезмәт итә, чөнки төрле чыганакларда бер үк балыкның төрле исем астында теркәлү очраклары күзәтелә.

Хезмәтнең әһәмияте шунда: монда телдә активрак кулланылган рус ихтионимнарының төрле чыганаклардан табып алынган татарча

эквивалентлары бирелгән. Мәсәлән, *бөкрәч – горбуша, сәврүк – севрюга, чуклы балык – султанка.*

Сүзлекнең отышлы ягы – атамаларга тулы һәм төгәл аңлатма бирү. Аңлатмаларда балык турында тулы мәгълүмат (аларның семьялыгы, яшәү ареалы, төсе, зурлыгы) китерелгән. Кайбер сүзлек мәкаләләрендә, өстәмә мәгълүмат буларак, теге яки бу төр балыкларның промыселда әһәмияте, аквариумда үстерелү, үрчетү мөмкинлеге, акклиматизацияләнү, саклану статусы күрсәтелгән.

Биологик сүзлекләрдә классификация атамаларын биргәндә төгәлсезлекләр, ялгышлар шактый очрый. Моның, әлбәттә, объектив сәбәпләре бар. О. Галимова исә, әлеге хаталарны мөмкин кадәр төзәтеп, ыруглар, семьялыклар, отрядлар, классларны (аскласс, өскласс) үзләреннән зуррак таксономик категорияләр аша аңлаткан. Атамаларга шул рәвешчә аңлатма бирү, бер яктан, хезмәтне энциклопедияләргә якынайтса, икенче яктан, зур гына мәгълүматны киң катлау укучыга кыска итеп җиткерергә ярдәм итәчәк. Бу, үз чиратында, хезмәтнең әһәмиятен тагын да арттыра.

Терминология бер өлкәгә караган атамаларда бермәгънәлелеккә ирешергә омтыла. Шуңа күрә, авторның сүзлектә классификация терминнарына зур игътибар бирүе, хезмәтнең икенче бер отышлы ягы булып тора.

Күпмәгънәле классификация терминнарында башта зуррак таксономик категорияне белдергән атамага, аннан ваграгына аңлатма китерелгән:

> **диңгез фәрештәләре** МОРСКИЕ АНГЕЛЫ *Squatinidae* 1) Скватинасыманнар отрядыннан, Атлантик, Тын океаннарның яр буе районнарында яшәүче балыклар семьялыгы; 2) *Squatina* Шул семьялыктан киң гәүдәле, зур канатлы, скатларга охшаш акулалар ыругы; диңгез фәрештәсе, кара фәрештә (*Squatina nebulosa*), зур күзле диңгез фәрештәсе һ.б. ны берләштерә.

Диалекталь атамаларны, татар телендәге төп орнитонимнарны аерып бирү дә сүзлек белән эшләүне җиңеләйтә, тел байлыгын ачып бирүгә хезмәт итә:

> **эт балыгы** ВЬЮН, ПИСКУН *Misgurnus fossilis* Эт балыклары семьялыгыннан; Үзәк һәм Көнчыгыш Европа сулыкларында яшәүче, сары күзле, сырты саргылт көрән, кара таплы, корсагы сары, ян-яклары кара полосалы, 25 см га кадәр озынлыктагы төче су балыгы; *диал.* **арыш балыгы, җылан балыгы, җылан балык, җылан этләйе, җылтай, җырнай, йылан балыгы, йылан балык, майма балык, мыжый, этекәч, этем, этләч балыгы, этбалык, этли, этли балык, этлүч, этмәй, этәнәй, ялтыр балык**

Ихтионимлы мәкаль-әйтемнәр сүзлеккә туплаган мәгълүматны милли мәдәни компонент белән баета. Алфавит тәртибендә бирелгән русча ихтионимнарның исемлеге (терминнар күрсәткече)

кулланучыларга кирәкле атаманың рус телендәге эквивалентын да табуны җиңеләйтә һәм сүзлекнең әһәмиятен арттыра.

О. Галимованың «Татарча-русча аңлатмалы балык атамалары сүзлеге», һичшиксез, уңай бәя алуга лаек.

Татар теленең үзенчәлекле лексик байлыгын туплаган, аңлатмаларында балыклар турында бай мәгълүматы булган әлеге хезмәт киң катлау укучыларга, биологлар, ихтиологлар, табигатьне саклаучылар, сүзлекчеләр, тәрҗемәчеләр, радио һәм телевидение, матбугат хезмәткәрләре, укытучылар өчен файдалы белешмәлек булып хезмәт итәчәк.

***Сабитова Илһамия Исламетдин кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының лексикография бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*